РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_22.06.2026 633-п

Саба муниципаль районы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү мәсьәләләре буенча төбәк ведомствоара комиссиясе турында» 2023 елның 30 мартындагы 790-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә Саба муниципаль районы Башкарма комитеты:

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия (алга таба - Комиссия) төзергә һәм расларга.

2. Саба муниципаль районы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәне расларга. (кушымта итеп бирелә).

3. Комиссия махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү буенча эшне координацияләүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

Җитәкче М.Р. Кәримов

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма
комитетының
«___» _________ 20
_______________карары белән
РАСЛАНГАН

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ МАХСУС ХӘРБИ ОПЕРАЦИЯДӘ КАТНАШУЧЫЛАРГА ҺӘМ АЛАРНЫҢ ГАИЛӘ ӘГЪЗАЛАРЫНА ЯРДӘМ ИТҮ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ БУЕНЧА ВЕДОМСТВОАРА КОМИССИЯ СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Кәримов М.Р. | Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Баһманов М. М. | Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары - икътисад бүлеге башлыгы, комиссия рәисе урынбасары |
| Гарипов И.Р. | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - Саба муниципаль районы Башкарма комитеты аппараты җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары |
| И.И. Котдусов | Башкарма комитет Җитәкчесенең инвестицион үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм итү буенча урынбасары - Саба муниципаль районының инвестицион үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм итү бүлеге башлыгы, комиссия рәисе урынбасары |
| Э.Ф. Багманова | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге башлыгы, комиссия сәркатибе |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Гайнетдинова Л. Н. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Саба муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Закиров Ф.Ф. | Саба һәм Теләче районнары буенча хәрби комиссар (килешү буенча) |
| Гатауллин Ф.К. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Мәүлетова А.М. | Саба муниципаль районында «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциясендә катнашучыларга ярдәм итү дәүләт фондының Татарстан Республикасы буенча филиалының социаль координаторы |
| Салимов И.Р. | Россия Федерациясе УФСИНның Татарстан Республикасы буенча УИИ Арча межмуниципаль филиалының өлкән инспекторы, эчке хезмәт капитаны (килешү буенча) |
| Хәбибуллин И. Г. | Саба районы буенча "Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү үзәге" ДКУ бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Шакиров И.Ф. | "Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе" МКУ башлыгы |

| | |
|---|---|
| Йосыпов М.Р. | "Саба район үзәк хастаханәсе" ДАССУ баш табибы (килешү буенча) |
| Саба муниципаль районының авыл (шәһәр) җирлекләре башлыклары (килешү буенча). | |

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма
комитетының
«___» _________ 20
________________карары белән
РАСЛАНГАН

**САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ МАХСУС ХӘРБИ ОПЕРАЦИЯДӘ КАТНАШУЧЫЛАРГА ҺӘМ АЛАРНЫҢ ГАИЛӘ ӘГЪЗАЛАРЫНА ЯРДӘМ ИТҮ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ БУЕНЧА ВЕДОМСТВОАРА КОМИССИЯ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге Нигезләмә Саба районы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссиянең вәкаләтләрен һәм эшчәнлеген оештыру тәртибен билгели (алга таба – комиссия).

1.2. Комиссия Саба муниципаль районы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү мәсьәләләре буенча эшчәнлек алып баручы муниципаль һәм башка оешмаларның гамәлләренең килешенгәнлеген тәэмин итү өчен төзелгән координация органы була.

1.3. Комиссия  Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты Указларына һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы законнарына һәм башка норматив хокукый актларына, Саба муниципаль районы Уставына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.4. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1.4.1 Саба муниципаль районы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм күрсәтү эшчәнлеген оештыру белән бәйле мәсьәләләрне карау;

1.4.2. Саба муниципаль районы территориясендә яшәүче махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларының, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) катнашучыларның гаилә әгъзаларының (алга таба – махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары), шул исәптән аларга социаль ярдәм, медицина һәм психологик ярдәм чаралары күрсәтелгәндә, алар өчен реабилитация, озак вакыт өйдә карау оештырылганда, эшкә урнашуда, белем алуда ярдәм иткәндә махсус хәрби операциядә катнашучыларны адреслы озата баруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәр эшләү;

1.4.3. Саба муниципаль районы территориясендә яшәүче махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларының мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләренә мониторинг ясау, мөрәҗәгатьләрне караганда Саба муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре эшен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

1.4.4. гражданнарны патриотик тәрбияләү өлкәсендә агарту эшчәнлеген оештыруга бәйле чаралар әзерләү;

1.4.5. махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә

әгъзаларын адреслы озата бару һәм аларга ярдәм чаралары күрсәтү мәсьәләләрен хәл иткәндә Саба муниципаль районы Башкарма комитетының, аның карамагындагы оешмаларның, башка оешмаларның ведомствоара хезмәттәшлеген оештыру.

## 2. Комиссиянең хокуклары

2.1. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

2.1.1. комиссия утырышларына Саба муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре вәкилләрен, шулай ук Саба муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр вәкилләрен чакырырга;

2.1.2. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләреннән, Саба муниципаль районы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалардан һәм иҗтимагый берләшмәләрдән Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча кирәкле материаллар соратып алырга;

2.1.3. махсус хәрби операциядә катнашучыларга аларның гаилә әгъзаларына ярдәм һәм башка төр ярдәм күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча Саба муниципаль районы Башкарма комитетының норматив хокукый актлары проектларын эшләүдә катнашырга;

2.1.4. комиссия компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча белгечләр һәм экспертлар җәлеп итәргә;

2.1.5. Комиссия карарлары материалларын һәм проектларын тәкъдимнәр эшләү, оператив һәм сыйфатлы әзерләү өчен эш төркемнәре төзергә, әлеге төркемнәрнең эш тәртибен билгеләргә;

2.1.6. Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм катнашучыларның гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары, шул исәптән конкрет затларга ярдәм күрсәтү турында Карары проектын әзерләргә.

## 3. Комиссия эшчәнлеген оештыру

3.1. Комиссия составы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи затлары, Саба муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Саба муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр вәкилләреннән төзелә.

3.2. Комиссия составына комиссия рәисе, комиссия рәисе урынбасары, комиссия сәркатибе һәм комиссия әгъзалары керә.

3.3. Комиссия рәисе комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә, аның эшен координацияли һәм оештыра. Комиссия рәисе булмаган чорда аның вәкаләтләрен комиссия рәисе урынбасарларының берсе башкара.

3.4. Комиссия секретаре:

3.4.1. комиссиянең чираттагы утырышы көн тәртибен һәм материалларын төзи;

3.4.2. комиссия утырышына кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча комиссия утырышы көн тәртибен раслау өчен комиссия рәисенә җибәрә;

3.4.3. комиссия утырышына кадәр ике эш көненнән дә соңга калмыйча комиссия әгъзаларына һәм кызыксынган затларга чираттагы комиссия утырышы көн тәртибе һәм материаллары белән таныштыра;

3.4.4. утырыш башланырга бер эш көненнән дә соңга калмыйча комиссия әгъзаларына утырышны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында хәбәр итә;

3.4.5. комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

3.4.6 комиссия утырышы йомгаклары буенча өч эш көне эчендә беркетмә әзерли һәм аны Комиссия утырышында рәислек итүчегә имзалау өчен тапшыра;

3.4.7. комиссия утырышын уздырган көннән алып ун эш көне эчендә комиссия карарларын материаллар тарату юлы белән комиссия әгъзаларына һәм башка кызыксынган затларга җиткерә;

3.4.8. комиссия карарының күчермәсен кабул ителгән карарны үтәү, тиешле

финанслау бүлеп бирү өчен Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карамагындагы оешмаларга, Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына, башка оешмаларга җибәрә.

3.5. Комиссия әгъзалары:

3.5.1 комиссия утырышларында катнашалар;

3.5.2. карала торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм киңәшләр проектларын әзерлиләр;

3.5.3. комиссия эшчәнлеген камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертәләр.

3.6. Комиссия утырышлары кирәк булганча, ләкин яртыеллыкка кимендә бер мәртәбә уздырыла.

3.7. Комиссия утырышы, анда комиссия составының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы дип санала.

3.8. Утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгрfalse комиссия карары өчен тавыш бирсә, комиссия карары кабул ителгән дип санала. Җәлеп ителә торган белгечләр һәм экспертлар тавыш бирү хокукына ия түгел. Комиссия карарларын кабул иткәндә, комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булган очракта, комиссия рәисе (утырышта рәислек итүче комиссия рәисе урынбасары) хәлиткеч тавыш хокукына ия.

3.9. Комиссия утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларны комиссия рәисе имзалый. Комиссия рәисе булмаган чакта беркетмәне комиссия рәисе урынбасарларының берсе имзалый.

3.10. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итү Саба муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.